01 ноябрь 2013 Казан ш. 10-35/кс №лы

***«Теплоснабсервис» ААҖ өчен эчәргә яраклы суга тарифларның билгеләнүе турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 07 декабрь 2011 416-ФЗ №лы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге дәүләт тарифларның көйләнүе турында» 13 май 2013 406№лы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Әлеге карарның кушымтасы буенча суык су тәэмин итүче «Теплоснабсервис» ААҖ өчен эчәргә яраклы суга тарифларны билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тариф карарның гамәлгә кергән көненнән башлап 31 декабрь 2013 елга хәтле гамәлдә булачак.
3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 январь 2013 6 №лы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге мәгълүматны ачу стандартлары буенча көйләнүнең чираттагы периодка тарифларның билгеләнүе турында карарның алынган көненнән башлап 30 календарь көненә хәтле «Теплоснабсервис» ААҖга мәгълүматны ачырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән ун көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 01 ноябрь 2013
10-35/кс №лы карарының
Кушымтасы

# Суык су тәэмин итә торган «Теплоснабсервис» ААҖ өчен эчәргә яраклы суга тарифлар

| № п/п | Муниципаль оешманың, суык су тәэмин итүче оешманың исеме, куллануч ыларның категорияләре | Эчәргә яраклы суга тариф, (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре | |
| 1 | «Теплоснабсервис» ААҖ | |
| | Яшәү секторындагы куллануч ылар<br>(тарифка НДС керми)* | 15,10 |
| | Башка куллануч ылар<br>(тарифка НДС керми) | 12,80 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексы 168нче пунктының тормышка ашырылуы максатыннан чыгып ассызыклана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге